| | |
|---|---|
| **Республика Татарстан**<br>**СОВЕТ**<br>**ЛЯКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО**<br>**ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО**<br>**МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА** | **Татарстан Республикасы**<br>**САРМАН**<br>**МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**<br>**ЛӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 31 нче март № 21

Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге Советының
аерым карарларының үз көчләрен
югалтуын тану турында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 18 статьясы, «Россия Федерациясе Президентының 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Указының 4 пунктын үтәү турында" Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 13.03.2026 елгы 09/13-09/1259 номерлы хаты, Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советы карарының үз көчен югалтуын танырга:

-«Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибен раслау һәм массакүләм мәгълүмат чараларына Сарман муниципаль районының «Лякинское сельское поселение» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү тәртибен раслау хакында» 2017 елның 19 августындагы 17 номерлы карарын;

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының 2021 нче елның 21 нче июлендә кабул иткән 8 нче номерлы карары «2017 елның 19 августындагы 17 номерлы Совет карары белән расланган «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру тәртибе һәм «Ләке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм башкарма комитет җитәкчесенең контракт буенча вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында массакүләм мәгълүмат чараларын бастырып чыгару өчен мәгълүмат бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында »;

- Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының 2022 нче елның 14 нче июлендә кабул иткән 12 нче номерлы карары « Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Советының керемнәр, мөлкәт һәм

мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүмат бирү хакында аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге Советы рәисе Ю. Г. Антонов